Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Ырынгы авыл җирлегенең Ырынгы авылында гражданнар җыены карары

16.11.2022 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Ырынгы авыл җирлегенең Ырынгы авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2023 елда Ырынгы авыл җирлегенең Ырынгы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 700 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Ырынгы авылында юлларны ремонтлауга юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Ырынгы авыл җирлегенең Ырынгы авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Ырынгы авыл җирлеге башлыгы _________ Р.И. Гордеев

Халык җыены секретаре _________ Р.Г. Шурбин